**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕ ШУМКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422653, с. Шумково,
ул. Центральная, дом 4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ШУМКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422653, Шумково,
Узэк урамы, 4 нче йорт,

Тел.: (84361) 26332, факс: (84361) 26332, e-mail:smk.rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноябрь 2024 ел Шумково авылы № 16-1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Хутор авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,
56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, республика Балык Бистәсе муниципаль районының «Шумково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы карар итәм:

1. 2024 елның 18 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Хутор авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Хутор торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (мобилизацияләнгән, хәрби хезмәткәрләр контракт, волонтерлар) һәм аларның гаилә әгъзалары һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- халык яшәгән район чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган юлларны төзү, ремонтлау һәм саклау;

- халык яшәгән территорияне яхшырту;
- урам яктырту урнаштыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шумково авылы, Үзәк урамы, 4 нче йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Укмас авылы, Үзәк урамы, 42 нче йорт; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы, Хутор авылы, Яшьләр урамы, 5 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Ошняк-Качкалак авылы, Югары урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырыла һәм Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати- телекоммуникация челтәрендә: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталындаИнтернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Башлыгы А.Р. Гилазиева